**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ НОВОАЛИМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423762, село Новое Алимово, улица Г.Тукая, дом 55.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423762, Яңа Әлем авылы . Г.Тукай урамы, 55 йорт.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ____________ КАРАР ________

«Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең аларның вазыйфаи урыннарына яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларына бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, аны реализацияләүдән (сатып алудан) һәм сатудан кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» 2014 елның 03 мартындагы 4 номерлы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон,«Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Әлем авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге Советы карарына «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең аларның вазыйфаи урыннарына яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларына бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, аны реализацияләүдән (сатып алудан) һәм сатудан кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» 2014 елның 03 мартындагы 4 номерлы карарына үзгәреш кертергә:

1.1. 2 өлешнең 2 абзацында «хәлиткеч тавыш хокукына ия» сүзләрен «даими (штат) нигездә комиссиядә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукына ия» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Яңа Әлем авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Яңа Әлем авыл җирлеге Советы рәисе Д.М.Әнвәрова